**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «29» декабреннән № 30-238

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм аларны үткәрү урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районың рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга тиеш .

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлауларны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында Бердәм порталда урнаштыру Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органының шәхси кабинетын кулланып гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру белән шөгыльләнүче Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) гавами тыңлауларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокта әзерләүне һәм үткәрүне башкаручы җирле үзидарә органының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.»;

1.2. 7 статьяның 7 өлешен түбәндәге эчтәлектәге биш абзац белән тулыландырырга:

« . Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үз күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләр тарафыннан, авторизациядән соң бердәм портал кулланып, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган бердәм идентификация һәм аутентификация системасы»федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә».

Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүче шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туган көне һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында мәгълүмат җибәрә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

1.3. 7 статьяның 11 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

1.4. 9 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгаруның һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруның район Уставы белән билгеләнгән тәртибе нигезендә гавами тыңлаулар уздырганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов